| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**СОВЕТ**<br>**Старосляковского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Иске Эсләк авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.07.2023 Иске Эсләк авылы № 38-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль
районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге территориясендә йорт хайваннарын
йөртү өчен билгеләнгән урыннарны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елның 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 27.12.2018 елның 498-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 15.05.2023 елның 02-06-2023/Прдп-208 номерлы күрсәтмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

*1) Иске Эсләк авылының көнбатыш өлеше Клуб урамыннан 50 метр ераклыкта;*

*2) Үтәгән авылының төньяк өлеше Мәктәп урамыннан 50 метр ераклыкта.*

2. Йорт хайванын йөртү өчен түбәндәге таләпләрне үтәргә кирәк:

1) автомобиль юлының йөрү өлешен кичкәндә, күп фатирлы йортларның гомуми файдаланудагы биналарында, мондый йортларның ишегалларында, балалар һәм спорт мәйданчыкларында хайванның ирекле, контрольсез хәрәкәт итү мөмкинлеген булдырмаска;

2) гомуми файдаланудагы территорияләрдә һәм урыннарда хайваннар эшчәнлеге продуктларын җыюны тәэмин итәргә;

3) Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге башкарма комитетының әлеге карары белән рөхсәт ителгән урыннардан читтә хайванны йөртүне булдырмаска

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,

Авыл җирлеге башлыгы Д.М.Әхмәтов